КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 25 май г.Казань № 639

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 август, 741 нче; /2020 ел, 23 ноябрь, 1049 нчы; 2020 ел, 19 декабрь, 1165 нче; 2021 ел, 11 май, 325 нче; 2021 ел, 31 май, 416 нчы; 2021 ел, 12 июнь, 446 нчы; 2022 ел, 3 июнь, 514 нче; 2022 ел, 11 июнь, 550 нче; 2022 ел, 20 декабрь, 1374 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту өчен Татарстан Республикасының муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башка бюджетара трансфертлар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган Авыл территорияләрендә торак төзелешен үстерү һәм биләмәләрне төзекләндерү дәрәҗәсен яхшырту өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 1 нче кушымтасында билгеләнгән

тәртиптә һәм шартларда торак төзү (сатып алу) өчен гражданнарга социаль түләүләр бирүне күздә тота торган, авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларын (алга таба шул ук эзлеклелектә – социаль түләүләр, чаралар) тормышка ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Башка бюджетара трансфертлар бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу критерийлары:

а) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында торак шартларын яхшырту чараларында катнашучылар исемлекләрен төзү, раслау һәм аларга үзгәреш кертү һәм авыл территорияләрендә торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклыклар бирү тәртибенең 3 нче кушымтасында бирелгән форма буенча социаль түләүләрдән файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлекләре (алга таба – исемлекләр) булу;

б) хисап чорына бу Кагыйдәләрнең 16 пунктында күрсәтелгән гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларын гамәлгә ашыру планын үтәү.»;

әлеге карар белән расланган Торак урын наемы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү (сатып алу) буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидияләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган Авыл территорияләрендә торак төзелешен үстерү һәм биләмәләрне төзекләндерү дәрәҗәсен яхшырту өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 2 нче кушымтасында билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда торак урын наемы шартнамәләре буенча гражданнарга бирелә торган торак урын (торак йорт) төзүгә (сатып алуга) бәйле чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү максатларында муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидияләр бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу критерийлары:

а) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карары белән расланган торак урыннар наемы шартнамәләре буенча торак алучы гражданнар

исемлекләрен төзү, раслау һәм аларга үзгәреш кертү тәртибенең 3 нче кушымтасында бирелгән форма буенча торак урын наемы шартнамәсе буенча чараларда катнашучылар исемлекләре һәм (яки) агымдагы финанс елында эш бирүче тарафыннан эш урынын биләүгә торак урыннар наемы шартнамәләре буенча торак алучы гражданнар җәлеп ителәчәк, булдырырга планлаштырыла торган яңа штат берәмлекләренең эш бирүче тарафыннан расланган һәм җирле үзидарә органы тарафыннан килештерелгән исемлеге (алга таба – исемлекләр) булу;

б) хисап чорына бу Кагыйдәләрнең 16 пунктында күрсәтелгән торак урын наемы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү (сатып алу) чараларын гамәлгә ашыру планын үтәү.»;

16 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы формасы буенча Министрлык тарафыннан расланган торак урын наемы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү (сатып алу) чараларын гамәлгә ашыру планы нигезендә торак урын наемы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү (сатып алу) чараларын гамәлгә ашыру турында хисаплар (алга таба – хисаплар) төзелә. Хисапларның формалары, аларны тапшыру сроклары һәм тәртибе Министрлык тарафыннан билгеләнә.»;

әлеге карар белән расланган Авыл территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле «в» пунктчасын өстәргә:

«в) хисап чорына бу Кагыйдәләрнең 16 пунктында күрсәтелгән авыл территорияләрен төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыру планын үтәү.»;

әлеге карар белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында торак шартларын яхшырту чараларында катнашучылар исемлекләрен формалаштыру, раслау һәм аларга үзгәреш кертү һәм авыл территорияләрендә торак төзелешенә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклыклар бирү тәртибендә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының 3 нче кушымтасында каралган, Авыл территорияләрендә торак төзелешен үстерү һәм биләмәләрне төзекләндерү дәрәҗәсен яхшырту өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренә теркәлә торган Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарга торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләүләр бирү турындагы нигезләмә (алга таба – Дәүләт программасы, Кагыйдәләр, Нигезләмә) нигезендә эшләнде һәм авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларында катнашучылар исемлекләрен төзү, раслау һәм аларга үзгәреш кертү тәртибен, авыл территорияләрендә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләү бирү турында таныклыклар (алга таба –

таныклык) бирү, шулай ук аларның гамәлдә булу срогын озынайту (социаль түләү өлешчә бирелгән очракта) тәртибен билгели.»;

5 пунктта:

«а» пунктчасының дүртенче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фондыннан» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан» сүзләренә алмаштырырга;

«г» пунктчасының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының территориаль органында иминләштерүче буларак теркәлү турында хәбәрнамәләр;»;

әлеге карар белән расланган Торак урыннар наемы шартнамәләре буенча торак алучы гражданнар исемлекләрен төзү, раслау һәм аларга үзгәреш кертү тәртибенең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары белән расланган «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының 3 нче кушымтасында каралган, Авыл территорияләрендә торак төзелешен үстерү һәм биләмәләрне төзекләндерү дәрәҗәсен яхшырту өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) теркәлә торган Авыл территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына торак урын наемы шартнамәсе буенча бирелә торган авыл территорияләрендәге торак урынны төзү (сатып алу) буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү  турындагы нигезләмәгә (алга таба шул ук эзлеклелектә – Дәүләт программасы, Кагыйдәләр, Нигезләмә) таянып эшләнде һәм торак урыннар наемы шартнамәләре буенча торак алучы гражданнарның исемлекләрен (алга таба – чараларда катнашучылар исемлекләре) төзү, раслау һәм аларга үзгәреш кертү тәртибен билгели.»;

әлеге карар белән расланган Квалификацияле белгечләр белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү кагыйдәләрендә:

7 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил юридик заты, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш.  Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре

капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

19 пунктта:

«а» пунктчасында «агымдагы финанс елның 31 декабренә» сүзләрен «заявка бирү датасына» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «агымдагы финанс елның 31 декабренә» сүзләрен «заявка бирү датасына» сүзләренә алмаштырырга;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Субсидия алучы килешү төзелгән көннән өч эш көне эчендә «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итү буенча дәүләт интеграцион мәгълүмат системасында электрон документ рәвешендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап төзи һәм субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куя.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин